*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 46**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Тел арты ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) унбер
   ә) болыннан
   б) төнге
   в) китапта

2. Тарихи сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) брейдер
   ә) сәгадәт
   б) алпавыт
   в) ризык

3. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) былтыр
   ә) быел
   б) кичә
   в) иртән

4. Җөмләдәге фигыльнең төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Олы ялкау бәләкәй ялкауны эшкә кушар*. (Мәкаль).
   а) хикәя фигыль
   ә) боерык фигыль
   б) хәл фигыль
   в) инфинитив

5. Ымлыкны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тик
   ә) ягъни
   б) түгел
   в) уф

6. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Татлы тел – җан азыгы.* (Мәкаль).

а) татлы
ә) тел
б) җан
в) азыгы

7. Җөмләдәге хәлнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Һәр эшнең ахырын уйлап эшлә*. (Мәкаль).

а) вакыт хәле
ә) рәвеш хәле
б) күләм хәле
в) максат хәле

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Холкы начардан дуслары качар*. (Мәкаль).

а) иярчен ия җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен тәмамлык җөмлә
в) иярчен аергыч җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган саннарны һәм сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Тел белеменең ____________ бүлеге сүзләрнең дөрес әйтелешен өйрәнә. Татар телендә ________ сузык аваз, ______ тартык аваз бар. Сингармонизм законының ике төре бар: рәт гармониясе һәм ____________ гармониясе. Предметның кемнеке булуын ____________ кушымчасы күрсәтә. Иярчен максат җөмлә баш җөмләнең максат ____________ урынында килә.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(12 балл)**

*На столе лежит тёплый хлеб. Он так вкусно пахнет!*

*Большой путь проделал хлеб. Сначала золотые руки зерно посеяли, урожай растили.*

*В золотом стебельке выросло зерно. Каждое утро серебряной росой умывался каждый колосок. Жаркое солнышка вбирало в себя каждое зёрнышко. Силой наливалось зерно.* (Т. Коломиец).

2. Табын түрендәге икмәк турында сез тагынниләр сөйли аласыз? Шул хакта фикерләрегезне 12 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. **(12 балл)**